**"Акыл фабрикасы" республикакүләм белем бирү форумы**

**12-14 ноябрь**

**ПРЕСС-РЕЛИЗ**

Чараны ТР Яшьләр эшләре министрлыгы ярдәме белән Бөтендөнья татар яшьләре форумы оештыра.




"Ачык университет" белем бирү платформасы 12-14 ноябрьдә узачак республикакүләм белем форумына чакыра. Өч көнлек программа дүрт юнәлешне колачлый: **IT**, **Заманча мәгариф, Этномәдәни проектларны үстерү һәм маркетинг, Мәдәният & Урбанистика**.

Катнашучылар өч көн дәвамында экспертлардан лекцияләр тыңлаячак, һөнәри остаханәләрдә белем алачак, дискуссияләрдә һәм воркшопларда катнашачак, кейслар чишәчәк.

"Ачык университет" платформасы – заманча белем бирү ресурсы, тел белеме, IT, PR, төбәкләр өйрәнү, мәгариф белгечләре белән очрашу урыны. Өч көнлек форум барышында тыңлаучылар каршында эшмәкәрләр, проект җитәкчеләре, блогерлар, маркетологлар, ТР Фәннәр академиясенең семиотика институты, Талантлар университеты, КАИ, Цифрлы трансформацияләр үзәге, төбәк инновацияле проектлар фонды хезмәткәрләре, шулай ук республиканың яшьләр министры һәм цифрлаштыру министры катнашачак.

"Ачык университет" мәктәп укучылары һәм студентлар өчен лекцияләрнең киңәйтелгән тупланмасын тәкъдим итә.

Өч көн – өч локация:
12 ноябрь – Ак барс банк лекторие (Уң як Болак урамы, 51),
13 ноябрь – Милли милли китапханә (Пушкин урамы, 86)
14 ноябрь – "Смена" заманча мәдәният үзәге (Шахиди урамы, 7).

Беренче көн (12 ноябрь 2021, Ак барс банк лекторие):

**IT**. Лекцияләр циклы дәвамында экспертлар татар IT-кластерлары, ясалма фәһем, СберКласс платформасына татар телен өстәү кейсы белән уртаклашачак.

Татарча ясалма фәһем турындагы хыялларны тормышка ашыру турында Татарстан Фәннәр академиясенең Семиотика институты вәкилләре **Җәүдәт Сөләйманов** һәм **Ринат Гыйльмуллин** сөйләячәк.

Ачык Университет координаторы **Райнур Хәсәнов** татарча IT-проектлар юлкүрсәткечен тәкъдим итәчәк.

Татар теле һәм мәдәниятенең интернеттагы хәләте турындагы дискуссиядә URBANTATAR радиосы авторы **Илһам Шәрипов**, ТР Фәннәр академиясенең Семиотика институты мөдире **Ринат Гыйльмуллин**, Иннополис университеты аспиранты **Альбина Хөсәенова**, КАИ үсеш һәм цифрлы трансформация проректоры **Айрат Хәсәнов**, ТР цифрлы трансформация үзәгенең проектлар һәм цифрлаштыру продуктлары җитәкчесе **Булат Габдрахманов**, АИРР төбәк инновацияле проектлар фонды җитәкчесе **Динар Насыйров** катнашачак. Чарага Татарстанның цифрлаштыру министры **Айрат Хәйруллин** чакырылган.

Икенче көн (13 ноябрь 2021, Милли китапханә):

**"ЭТНОМӘДӘНИ ПРОЕКТЛАРНЫ ҮСТЕРҮ ҺӘМ МАРКЕТИНГ"** – социаль челтәрләр белән эшләү, икетелле аудитория белән коммуникация булдыру үзенчәлекләре турында лекцияләр, заманча проектларның маркетинг стратегияләре. Форумда катнашучылар Fragency SMM-агентлыгына нигез салучы **Регина Фасхеева**; Creeptone Media нигез салучыларының берсе, арт-менеджер **Айгөл Дәүләтшина;** "Нур" фестиваленең PR, SMM и маркетинг җитәкчесе, "Кайтам" проектының баш мөхәррире **Альбина Закируллина**; "Әлиф" иҗат төркеме администраторы **Алена Батуллина**, "Тәртип" радиосының PR бүлеге җитәкчесе **Айсылу Лерон**, "Ялкын" журналының веб-редакторы **Гүзәл Закирова**, блогер **Ләйлә Лерон**, Милли китапханә мөдире урынбасары **Тәбрис Яруллин** һәм "Че гуглит татар кызы" каналы авторы **Динара Зиннатова** белән татар проектларын таныту турындагы дискуссиядә фикер алышачак.

**"МӘГАРИФ"** – бердәм дәүләт имтиханы, фән белән шөгыльләнү, чит ил уку йортларына керү, эш эзләү һәм резюме төзүгә багышланган махсус дискуссияләр һәм остаханәләр циклы.

"XXI гасырда югары белем кирәкме?" дискуссиясендә катнашырга Татарстанның яшьләр министры **Тимур Сөләйманов**, Талантлар университетының башкарма мөдире **Айдар Акмалов**, Казан мәгариф идарәсенең аналитика бүлеге эксперты, "Җанлы китап" проекты авторы **Алия Салихҗанова**, "Ачык Университет" проекты кураторы **Зөһрә Вилданова**, Татарстанның Дәүләт шурасы депутаты, "Бала-Сити" белем бирү оешмасының мөдире **Альбина Насыйрова** чакырылды.

Өченче көн (14 ноябрь 2021, "Смена"):

**"МӘДӘНИЯТ & УРБАНИСТИКА".** Форум йомгакланыр алдыннан катнашучылар өчен Пеләтән һәм Яңа бистә буйлап экскурсия уздырыла. Шәһәр мохитен яңача төшенүгә багышланган воркшоп барышында проектларны тәкъдим итү үрнәкләре күрсәтеләчәк; катнашучылар, төркемнәргә бүленеп, музей, ресторан, экскурсия һәм чара темаларына эшләр башкарачак. Форумның әлеге бүлегендә Казанның үзенчәлекләре моделе, Чәкчәк музее, ZYAB.PROJECT һәм Екатеринбур каласының татар бистәсе проекты тәкъдим ителәчәк.

Чаралар ике телдә уза. Форумда белем алучыларга "Ачык университет" сертификатлары тапшырылачак.

**Ничек катнашырга?**

Катнашу түләүсез, форумның һәр блогына алдан аерым теркәлергә кирәк. Шулай ук онлайн трансляция оештырылачак.

Форум чараларына алдан язылу формалары:

IT (12 ноябрь 2021)

ОБРАЗОВАНИЕ (13 ноябрь 2021)

МАРКЕТИНГ И ПРОДВИЖЕНИЕ ЭТНОКУЛЬТУРНЫХ ПРОЕКТОВ (13 ноябрь)

КУЛЬТУРА & УРБАНИСТИКА (14 ноябрь)

Чыгышларның тәртибе һәм тулы тасвирламасы TATFORUM һәм АЧЫК УНИВЕРСИТЕТ аккаунтларына урнаштырылачак.

*Оештыру һәм хезмәттәшлек:*
*тел. +7 937 618-04-09 (Зөһрә Вилданова)*
*e-mail: zuhvildany@gmail.com*

*Аккредитация:*
*тел. +7 916 709-78-42 (Римма Гомәрова)*
*e-mail: prtatforum@gmail.com*

---

"Ачык университет" платформасы – заманча белем бирү ресурсы, профессиональ экспертлар белән очрашу урыны.

Проект 2019 елда Бөтендөнья татар яшьләре форумының "Акыл фабрикасы" нигезендә булдырыла. Тарих, заманча мәдәният темасына лекцияләр курсын **Фаяз Хуҗин**, **Гамирҗан Дәүләтшин**, **Дамир Исхаков**, **Хатыйп Миңнегулов**, **Илнур Миргалиев** һәм башка галимнәр укый. Хәзерге көндә "Ачык Университет" нигезендә онлайн университет буларак эшли, шул ук вакытта экологик һәм тарихи экскурсияләр оештыра. Университет сайтында татар телендә милли дизайн, тәрбия, тарих, PR һәм башка юнәлештәге онлайн курслар урнаштырылган.

АКЫЛ ФАБРИКАСЫ
AÇIQ UNİVERSİTET